КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 июль г.Казань № 634

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурслары турында» 2018 ел, 1 октябрь, 889 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурслары турында» 2018 ел, 1 октябрь, 889 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 март, 164 нче; 2021 ел, 21 июнь, 492 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җиңүчеләр санын һәм акчалата бүләкләү күләмнәрен түбәндәгечә билгеләргә:

«Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы буенча:

«Дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы һәм коммерциячел булмаган оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» номинациясе буенча өч җиңүче билгеләнә:

1 урын – 1 000 мең сум;

2 урын – 750 мең сум;

3 урын – 500 мең сум;

«Авыл җирлегендәге җирле үзидарә органының – Татарстан Республикасы муниципаль архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» номинациясе буенча алты җиңүче билгеләнә, һәр җиңүчегә акчалата бүләкләү күләме 375 мең сум тәшкил итә;

«Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы буенча өч җиңүче билгеләнә:

1 урын – 1 000 мең сум;

2 урын – 750 мең сум;

3 урын – 500 мең сум.»;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләргә акчалата бүләкләү түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен.»;

әлеге карар белән расланган «Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» һәм «Коммерциячел оешманың – атарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсларының конкурс комиссиясе составындагы Роза Шәйхәйдәр кызы Әхмәдиеваның вазыйфа исеменә «, Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга «Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләргә акчалата бүләкләү түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган «Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң

яхшы архивы» республика конкурсы турындагы нигезләмәнең 3.7 пунктындагы өченче абзацыннан һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы турындагы нигезләмәнең 3.7 пунктындагы өченче абзацыннан һәм 5.2 пунктындагы икенче абзацыннан тыш, әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин